# ӘНКӘЙ ГӨЛЕ

*В.АГАПОВ көе*
*М.РАЗОВ шигыре*

Чит җирләрдә гомер кичерәбез,
Тынгы бирми сагыш йөрәккә.
Сагынганда гына карарсыз, дип,
Гөл җибәргән әнкәй бүләккә.

*КУШЫМТА:*
Гөл җибәргән, гөл җибәргән
Әнкәй, боекмагыз,
Йөремәгез, диеп, моңаеп.
Авыр чакта киләм гөл каршына,
Әнкәй карый сыман елмаеп.

Әнкәй гөле һәрчак яшел килеш,
Күз карасы кебек саклыйбыз
Өебездә шушы гөлдән изге,
Кадерлерәк әйбер тапмыйбыз.

Чәчәк ата язлар җиткән саен,
Күңелләргә тула наз, рәхәт.
Үзең кебек безгә бәхет биргән
Гөлең өчен, әнкәй, мең рәхмәт.